**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2026 елның 2 марты 23 -РС номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023елның 08 декабрендәге 119-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы, 2026 елның 26 февралендәге 16-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 171 статьялары һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2023 елның 8 ноябрендәге 119-РС номерлы карары (2024 елның 28 октябрендәге 88-РС номерлы соңгы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 бүлекнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типлаштырылган квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш, вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен; авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы

яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.»;

2) 20 бүлектә:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда белешмәләрне тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар аларның керемнәренә чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм формада» белешмәләр тапшырырга тиеш.;

в) 3 өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 5 өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге бүлек нигезендә тапшырыла торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга;

е) 6 өлештә «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге бүлек нигезендә тапшырыла торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 7 өлештә «үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турынд» сүзләренә алмаштырырга, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда каралган чыгымнар хакында белешмәләр,";

з) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар статьяның әлеге бүлегенең 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыралар, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге бүлекнең 1 һәм 1.1 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) тапшыралар.»;

и) 12 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

к) 14 өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 22 өлешнең 3 өлешендәге 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. „Коррупциягә каршы көрәш турында“ Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе А.Ә. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**